| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ**

_______15.12.2025_______ №___266-од__________

г. Казань

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында» 2024 елның 25 июлендәге 116-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында» 2024 елның 25 июлендәге 116-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Методик семинарлар үткәрү графигы ел саен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнә һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгында күрсәтелгән методик семинарларның беренче датасына кадәр кимендә җиде эш көне кала ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән катнашучыларга җиткерелә.»;

6.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Фестивальнең муниципаль этабын үткәрү графигы ел саен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнә һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгында күрсәтелгән муниципаль этапны үткәрүнең беренче датасына кадәр кимендә җиде эш көне кала ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән катнашучыларга җиткерелә.»;

7.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Видеочыгыш ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгында күрсәтелгән муниципаль этапны үткәрүнең

беренче датасына кадәр кимендә җиде эш көне кала ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына җибәрелә.

Видеочыгышның әлеге Нигезләмәнең 6.4. пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килүен тикшерү ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан аның керү көнендә үк тикшерә.»;

8.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. 2 этап – зона этабы – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә үткәрелә.

Фестивальнең зона этабын үткәрү графигы ел саен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнә һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгында күрсәтелгән зона этабын үткәрүнең беренче датасына кадәр кимендә җиде эш көне кала ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән катнашучыларга җиткерелә.

Фестивальнең зона этабы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлектә зоналарга түбәндәгечә бүленеп оештырыла һәм үткәрелә:

1 зона. Аксубай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары;

2 зона. Азнакай, Актаныш, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Сарман, Тукай, Чистай муниципаль районнары

3 зона. Әгерҗе, Арча, Алабуга, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Саба муниципаль районнары, Чаллы шәһәре;

4 зона. Апас, Әтнә, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Зеленодольск, Кайбыч муниципаль районнары;

5 зона. Алексеевск, Әлки, Кама Тамагы, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Спас, Тәтеш, Теләче муниципаль районнары;

6 зона. Казан шәһәре – Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе, Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе, Совет районы администрациясе.

Фестивальне үткәрү зоналары (муниципаль берәмлекләр) ел саен күчә торган график буенча үзгәртелә.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова